ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2024 ел Баулы шәһәре № 155

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 59 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренә, хезмәт хакын түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 2 өлеше, Татарстан Республикасының 2006 елның 22 февралендәге 15-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына, мәгариф өлкәсендә, Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Законы, «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

К А Р А Р И Т Ә :

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 59 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренә, хезмәт хакын түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

II «Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләре хезмәтенә түләүне билгеләү» бүлегендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ структурасындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең база окладлары, түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Аена база окладды күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр)әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яисә «дипломлы белгеч» квалификациясе бирелү белән раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 18405,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 18410,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик | - | - | 18550,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (начальнигы) урынбасары;<br>Муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы структур бүлекчә мөдире (начальнигы) | | | |

V «Кызыксындыру характерындагы түләүләр» бүлегендә:

3.3. пунктының 10 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе, «Телләрне, мәдәниятне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» күкрәк билгеләре булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. Татарстан Республикасы «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе, «Телләрне, мәдәниятне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» күкрәк билгеләре булган өчен өстәмә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министры (Татарстан Республикасы мәгариф Министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.»;

«Мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган дәүләт һәм ведомство бүләкләре исемлеге» карарга Кушымтада:

«Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегендә:

1 пунктны 1.8. - 1.11. пунктчалары белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «1.8. | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләр тәрбиясе өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. | Мәгариф отличнигы |
| 1.11. | Россия Федерациясенең мактаулы тәрбия һәм белем бирү хезмәткәре ». |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарсан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров